КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 апрель г.Казань № 311

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибен билгеләү турында» 2016 ел, 9 июнь, 378 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 18 октябрь, 943 нче, 2020 ел, 29 июль, 632 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Бүлмәләрнең милекчеләре исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар катнашында күпфатирлы йортта гомуми мөлкәтне капиталь ремонт буенча башкарылган эшләрне һәм (яки) күрсәтелгән хезмәтләрне кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктның икенче абзацында «төбәк дәүләт торак күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле (алга таба - төбәк дәүләт торак күзәтчелеге)» сүзләренә алмаштырырга;

3.3 пунктта:

икенче абзацта «төбәк дәүләт торак күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «төбәк дәүләт торак күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле» сүзләренә алмаштырырга;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымтада «төбәк дәүләт торак күзәтчелеге функцияләрен гамәлгә ашыручы» сүзләрен «төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында территорияләрне комплекслы үстерү проектларын тормышка ашыру чаралары турында» 2021 ел, 24 сентябрь, 913 нче карары белән расланган Торак йортлар салынган территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә урнашкан күпфатирлы йорттагы барлык урыннарга милек хокукы күчкәннән соң, махсус счет хуҗасы тарафыннан хокукны Татарстан Республикасының яки муниципаль берәмлекнең махсус счетына тапшыру тәртибенә, 7 пунктта «дәүләт торак күзәтчелеге органнарына» сүзләрен «төбәк дәүләт торак контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органына» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин